**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы торак пунктында**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

"26" ноябрь 2025 ел. № 2

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» гы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы торак пунктында халык җыены

**КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылы территориясендә 2026 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 нче төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Урамнарны яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм подстанция мәйданчыкларын, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (урам яктырту өчен лампалар, автоматлар,җибәрү җайланмалары, таймерлар сатып алу һәм урнаштыру, эш һәм хезмәтләр өчен түләү).
2) Торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (балалар мәйданчыгын койма белән әйләндереп алу, материаллар сатып алу һәм урнаштыру, Киров урамындагы су үткәрү торбасын ремонтлау, материаллар сатып алу, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү, үләннәрне чаптыру, чистарту, эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү).
3) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту: (вак таш сатып алу , Молодежная һәм Мирная урамнарына салу, транспорт хезмәтләре һәм эш өчен түләү).
4) Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне)төзекләндерү: (Молодежная урамындагы чишмәне ремонтлау, чистарту , эш һәм хезмәтләр өчен түләү)

Экономия ясалган очракта, Күңгәр авыл җирлеге башкарма комитетына халыктан җыелган акчаны җыенда каралган башка мәсьәләләрне хәл итүгә тотарга рөхсәт итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлегенең Түбән Шашы авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Күңгәр авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4 Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күңгәр авыл җирлеге Түбән Шашы авылында узган халык җыены карарын "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Күңгәр авыл җирлеге башлыгы: Рәхимҗанова Г.И.